Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Татар Казысы авыл җирлеге Советы

Татар Казысы авыл җирлеге башлыгы
**КАРАРЫ**

02 февраль, 2026 ел № 2

Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә, Питрәч муниципаль районының 2017 елның 21 августындагы 60 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлегендә (2017 елның 12 декабрендәге 73 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 84 номерлы, 2019 елның 20 сентябрендәге 121 номерлы, 2022 елның 14 декабрендәге 552 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 5562 номерлы үзгәрешләр белән) гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе хакында нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1. Түбәндәге проект буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә:

- Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Татар Казысы, Казиле авылы, Луговая урамы адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Татар Казысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре индивидуаль торак төзелеше (Ж1) зонасында «дини йолаларны гамәлгә ашыру» - кадастр номеры 16:33:110201:57 булган, 36140 кв.м мәйданлы җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы проекты.

2. Гавами тыңлаулар уздыруны оештыручыны - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге башкарма комитетына гавами тыңлаулар оештыручыларга җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлаулар оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү 2026 елның 27 февраленнән дә соңга калмыйча төгәлләнергә тиеш дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Татар Казысы авыл җирлеге башлыгы Ф. Г. Кәримуллин